ЧӘРШӘМБЕ
10 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 8 (5808)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

АГИТАЦИЯ-МАССА ЭШЕН НЫГЫТУ ӨЧЕН

„Хезмәт ияләре депутатларының край, өлкә, округ, район, шәһәр, авыл һәм поселкы Советларына сайлауларның нәтиҗәләре“ турында газетабызның 6 нчы номерында урнаштырылган маглүмат—бу политик әһәмияткә ия булган гаят зур документ. Бу документның һәрбер җөмләсе, һәрбер сүзе, һәрбер цифры коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогының гүзәл җиңүләре турында, дөньяда иң демократик Конституция—Сталин Конституциясе нигезендә үткәрелгән сайлауларның бөек уңышлары турында сөйлиләр.

Бөтен Советлар Союзы буенча исемлеккә теркәлгән 93 миллион 547 мең 797 сайлаучыдан тавыш бирүдә 92 миллион 812 мең 237 кеше катнашты. Бу, сайлауларда катнашырга тиеш булган кешеләр санының 99,21 процентын алып тора. Хезмәт ияләре депутатларының өлкә Советларына күрсәтелгән кандидатларга—коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы кандидатларына сайлауларда катнашкан барлык сайлаучыларның 99,02 проценты; район советларына күрсәтелгән кандидатларга—98,72 проценты; шәһәр Советларына күрсәтелгән кандидатларга—98,04 проценты, авыл һәм поселкы Советларына күрсәтелгән кандидатларга — 98,04 проценты тавыш бирде. Татарстан АССР буенча тавыш бирү өчен хокуклары булган 1.441.570 сайлаучыдан хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларда тавыш бирүдә 1.424.157 кеше катнашты. Бу,— сайлаучыларның гомуми санының 98,8 проценты дигән сүз. Тавыш бирүдә катнашкан барлык сайлаучыларның 97,6 проценты коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы кандидатларына тавыш бирде. Барлык сайланган депутатлар—коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары. Бу,— совет халкының политик-мораль бердәмлегенең, үзенең алдынгы отряды тирәсенә, Ленин—Сталин партиясе тирәсенә, бөек юлбашчысы иптәш Сталин тирәсенә нык тупланганлыгының, коммунизм эшенә чиксез бирелгәнлегенең иң зур һәм иң гүзәл күрсәткече.

Бөек Ватаныбызның барлык республикаларындагы, край, өлкәләрендәге кебек үк, безнең орденлы Татарстан республикасында да хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар гаят зур күтәренкелек һәм бердәмлек белән үтте. Бу—Ленин—Сталин милли политикасының бөек тантанасы. Ленин—Сталин партиясенең бер отряды булган Татарстан партия оешмасы сайлауларга хәзерлек һәм аны үткәрү вактында хезмәт ияләре арасында политик-масса эшен гаят киң җәелдерде. Җәмагат эшендә актив катнашучы тагын да яңа кадрлар үсеп чыктылар. Сайлау комиссияләрендә 125 меңнән артык кешенең актив катнашуы үзе генә дә зур факт!

Сайлау кампаниясе вактында республикабызда агитатор, пропагандист һәм доверенный булып 70 меңнән артык кеше эшләде. Болар массаларга заманыбызның иң гүзәл документын—Сталин Конституциясен, дөньяда иң демократик Конституция нигезендә төзелгән сайлау законнарын аңлатуда, халыкара хәл турында, хөкүмәтебезнең һәм партиябезнең карарларын аңлатып бирүдә, дингә каршы пропаганда алып баруда зур эшләр башкардылар. Бөтен дөнья хезмәт ияләренең бөек юлбашчысы, остазы, атасы, иң кадерлесе һәм иң якын дусты иптәш Сталинның тууына 60 ел тулу көне сайлау көннәре белән бергә туры килгәнлектән, бу ике зур бәйрәм халыкның бөек тантанасына әйләнделәр. Агитаторлар, пропагандистлар бөек юлбашчыбызның мактаулы һәм чиксез гүзәл тормыш һәм көрәш юлын киң массага гаят зур энтузиазм һәм күтәренкелек белән аңлаттылар.

Агитатор, пропагандист һәм доверенный сайлаулар вактында сайлаучыларның киңәшчеләре, аларның иң якын дуслары булып әверелделәр, хезмәт ияләре аларны күтәп алдылар, аларга зур ихтирам белән карадылар, аларның һәрбер сүзен зур игтибар белән тыңладылар. Бу шулай булырга тиеш тә, чөнки агитатор, пропагандист — ул массаларга большевистик турылык сүзен җиткерүче, партиянең иң ышанычлы кешесе. Шунлыктан, агитаторлар белән системалы рәвештә эш алып бару, аларга конкрет ярдәм итү партия оешмаларының төп бурычы булырга тиеш.

Сайлаулар вактында гаят зур политик-масса эше алып барылды, бу эштә бай тәҗрибә тупланды. Хәзер төп бурыч—хезмәт ияләрен политик тәрбияләүнең зур коралы булган агитация-пропаганда эшендәге бу зур уңышларны һәм бай тәҗрибәләрне саклап калуда, аларны ныгытуда һәм тагын да киңәйтүдә. Сайлау кампаниясе үтте дигән сүз агитация-масса эшенең әһәмияте кимеде дигән сүз түгел, әлбәттә. СССР Верховный Советына, союзный һәм автономияле республикаларның Верховный Советларына сайлаулар кампаниясе үтү белән күп кенә оешмалар агитация эшләрен йомшартып җибәргәннәр иде. Ә кайберләре бөтенләй бу эшне онытканнар иде. Агитация-масса эшләрен йомшартуга алып бара торган мондый зарарлы настроениеләргә юл куелмаска тиеш, киресенчә, сайлау кампаниясе чорында агитация-масса эшләре буенча тупланган тәҗрибәләрне ныгытырга, бу эшне тагын да киңәйтергә кирәк.

Сайлаулар вактында большевистик матбугат агитация-масса эшендә зур уңышларга иреште, без бу уңышларны ныгытырга һәм аларны тагын да киңәйтергә тиешбез.

Агитация-пропаганда эшенең барлык формалары—лекцияләр, докладлар, митинглар һәм агит-коллективлар, агитаторлар өчен семинарлар,—болар барсы да сайлаулардан соң да сакланырга тиешләр. Агитация-масса эшенең төп эчтәлеге—партиябезнең XVIII нче съезды карарларындагы һәм иптәш Сталин докладындагы бөек идеяләрне халыкның киң массасына аңлатуны, бу карарларны уңышлы рәвештә үтәү өчен миллионнарны туплауны, халыкара хәл турындагы мәсьәләләр белән хезмәт ияләрен әледән-әле таныштырып баруны, хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүне һәм кешеләрнең аңындагы капитализм калдыкларына каршы көрәшүне һәм башка шуның кебек мәсьәләләрне үз эченә алырга тиеш. Агитация-масса эшләре һәр вакытта да производство бурычлары белән, илебезнең оборона куәтен тагын да ныгыту бурычлары белән бергә бәйләп алып барылсын.

Пропаганда һәм агитация работникларының шушы көннәрдә булып үткән өлкә киңәшмәсе хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауның йомгакларын һәм агитация-масса эшенең бурычлары турындагы мәсьәләне тикшерде. Бу эшкә йомгак ясады. Хәзер безнең бурыч—сайлау кампаниясе вактында ирешелгән барлык уңышларны, бай тәҗрибәләрне туплаудан, аларны ныгытудан тагын да киңәйтүдән гыйбарәт.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

8 нче гыйнварда фронтта әйтерлек бер нәрсә дә булмады.

Ухта, Реболы һәм Петрозаводск юнәлешләрендә—разведка отрядларының хәрәкәтләре.

Карелия бугазында разведчикларның эзләнүләре, мылтыктан, пулеметтан һәм артиллериядән атышу.

Һава начар булганлыктан безнең авиация күзәтү очышлары гына ясады.

Казанда „Ширпотреб“ артеленең тегү цехында машинада тегүче стахановчы Н. Д. Бакаев иптәш эшләп чыгару нормасын һәр айны уртача 250 процент үтәп килә.
И. Галиев фотосы.

„Седов“ мачтасындагы утны ачык күрәбез

„И. СТАЛИН“ БОЗВАТКЫЧЫ БОРТЫ, 8 гыйнвар. (Радио. ТАСС). Көньяк юнәлештәге көчәеп бара торган җил бозларны бераз аерды. Бозваткыч алдында ярык килеп чыкты. Шушыннан файдаланып „И. Сталин“ бозваткычы бүген сәгат 1 дә яңадан „Седов“ка таба бара башлады. Иртәнге 9 сәгатькә кадәр ике миль ярым чамасы ара үттек, ләкин тагын да 2—3 метр калынлыктагы, күп еллык, иске, тоташ боз кырына очрадык. Аны үтеп чыгарга тырышабыз. Бер удар белән бозваткыч 7—8 метр үтә.

Алда „Седов“ мачтасындагы утны бик ачык күрәбез.

И. Папанин.

Седовчыларга бөтенләй якынайдык

„И. СТАЛИН“ БОЗВАТКЫЧЫ БОРТЫ, 8 гыйнвар. (Радио. ТАСС). Бүген иртән 11 сәгатьләр чамасында боз ватуны туктатырга һәм үзебез тукталырга мәҗбүр булдык. Безнең алда гаят зур боз кыры. Флагман хәлнең яхшыруын көтеп туктап тора. Седовчыларга бөтенләй үк якынайдык. Алар безнең белән очрашуга хәзерләнәләр һәм безнең янга җәяү килергә бик телиләр. Безнең бозваткычта да „Седов“ янына җәяү барырга рөхсәт сораучы энтузиастлар бик күп. Моңа мөхтаҗлык юк.

Седовчылар барсы да сау-сәламәт, үзләрен яхшы хис итәләр.

Капитан Бадигин аю балалары итеннән пешерелгән отбивной котлетларны канәгатьләнеп ашауларын хәбәр итә. Без килгәнгә кадәр барсын да бетерү белән „куркыта“.

Седовчыларның юлдашлары—этләр карабтан еракка ук китеп безнең якка карап өрәләр.

20 сәгаттә боз азрак кына ярылды. Дөрес, ул ярык „Седов“ка таба бару юлында түгел, ләкин без „Седов“ка таба бару юлын эзләп яңадан алга кузгалдык.

22 сәгаттә бозлар яңадан өелә башлады. Җилнең үзгәрүен көтеп туктарга мәҗбүр булдык.

И. Папанин.

„СЕДОВ“ ХӘРӘКӘТЕ РАЙОНЫНДА

„СЕДОВ“ БОЗВАТКЫЧЫ БОРТЫ, 9 гыйнвар. (ТАСС ның махсус хәбәрчесеннән радио). Кичә „Седов“ хәрәкәте районында үзгәрүчән болытлы, вакты белән томанлы булды. Тимпература иртә белән минус 4,3 градус, кич белән плюс 1 градус булды. Иртә белән 5 балл көчендәге төньяк-көнбатыш җиле исте, кичкә таба ул көньяк җиленә күчте һәм 7 баллга кадәр көчәйде.

Координатларны билгеләдек: төньяк киңлек 80 градус 46,4 минут, көнчыгыш озынлык 02 градус 28 минуты. Суднодан 500 метр чамасы ераклыкта бозлар ярыгы күренә. Уң як борттагы ярык тагын 2—3 метрга аерылды.

Суднода эш яхшы бара, машина бүлегендә һәм палубада агымдагы эшләр алып барыла. Экипажның настроениесе күтәренке.

Н. Бекасов.

Күптән түгел конфликт булган районда Монголия Халык Республикасы белән Манчжоу-Го арасында чикне төгәл билгеләү буенча катнаш комиссиянең бергәләп белдерүе

Катнаш комиссиянең тугызынчы утырышы 1940 нчы елның 7 нче гыйнварында, Харбин шәһәрендә, Япония — Манчжоу-Го делегациясе урнашкан „Новый Харбин“ отелендә, Манчжоу-Го хөкүмәте уполномоченные Камеяма әфәнде председательлегендә булды.

Карта буенча чикне төгәл билгеләү турындагы мәсьәләне тикшерү дәвам итте.

Алдагы утырыш 10 нчы гыйнварда, Совет—Монголия делегациясе урнашкан бинада булачак.

МОСКВА—БЕРЛИН АВИАЛИНИЯСЕНДӘ БЕРЕНЧЕ РЕЙС

8 нче гыйнварда, иртән 10 сәгать 45 минутта, Москва белән Берлин арасындагы халыкара һава юлы буенча сынау рейсенә Москвадан күп урынлы һәм тиз очышлы пассажир самолет очып китте. Самолетның бортында—экипажның командиры, беренче класс пилот иптәш Кириченко, пилотлардан Смирнов һәм Хорпяков иптәшләр, бортмеханик иптәш Монахов һәм бортрадист иптәш Глушаев.

Москва белән Берлин арасында һава юлы буенча тәртипле хәрәкәт 21 нче гыйнварда башлана. Яңа авиатрасса Минск, Белосток, Кенигсберг һәм Данциг аркылы үтә. Аның гомуми озынлыгы—1.855 километр. Шушы бөтен юлны самолетлар 8 сәгать 10 минутта үтәргә тиешләр.

12 нче гыйнварда Берлиннән Москвага шундый ук рейскә Германия самолеты чыгачак. Совет ягыннан икенче сынау очышы 16 нчы гыйнварда булачак. (ТАСС).

ЛЬВОВ ӨЛКӘСЕНДӘ СОВХОЗЛАР

ЛЬВОВ, 9 гыйнвар. (ТАСС). Өйәз үзәге Броды шәһәреннән ерак түгел генә элекке алпавыт имениесендә Львов өлкәсендә беренче совхоз төзелә. Аның 1.800 гектар җире бар. Совхоз колмак җитештерүгә специаллаша.

Өлкә җир бүлеге берничә терлекчелек совхозы оештырырга хәзерләнә башлады.

Йөзпотчылар ЯРЫШЫ

ҺӘР ГЕКТАРДАН 110 ПОТ УҢЫШ АЛУ ӨЧЕН

Буденный районының „Красный Яскуль“ колхозы үткән ел югары иген уңышы алды. Бодай уңышы аерым участкыларда гектарына уртача 22,5 центнерга житте. Житеннең һәр гектарыннан 38 центнер орлык уңышы чыкты.

Колхозчылар Калинин районы алдынгыларының мөрәҗәгатен тикшергәч, быел һәр гектардан 110 пот уңыш алу бурычын куйдылар. Моның өчен хәзер колхозда ныклы хәзерлек эшләре алып барыла.

Колхозчылар язгы чәчүгә зур оешканлык белән хәзерләнәләр. Авыл хуҗалыгы машиналарына һәм инвентарына ремонт ясау төгәлләнде. Ремонтның сыйфаты яхшы. Җирле ашламалар җыю уңышлы бара. 600 центнер компост хәзерләнгән. Басуга 666 йөк тирес чыгарылды.

Бу колхоз Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы күргәзмәсенә катнашу өчен кандидат итеп теркәлде.

А. Яфизов.

ЙӨЗПОТЧЫЛАР МӘКТӘБЕ

Гектарыннан йөз пот иген уңышы алуга ирешү турында Калинин районы колхозчыларының мөрәҗәгатен „Активист“ колхозы (Норлат районы, Тат. Танай авылы) колхозчылары зур дәрт белән каршы алдылар һәм быел бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача кимендә 101 пот иген уңышы алуга ирешүне йөкләмә итеп алдылар. Бригадалар һәм колхозчылар арасында социалистик ярыш договорлары төзелде. Колхозда колхозчыларның агротехника буенча белемнәрен күтәрү өчен „Йөзпотчылар мәктәбе“ исемендә түгәрәк оештырылды. Түгәрәк занятиеләренә колхозчылар зур кызыксыну белән йөриләр.

Җәләлев.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК ТӨГӘЛЛӘНДЕ

Теләче районы колхозларында 1940 нчы елда һәр гектардан 100 пот иген уңышы алу өчен көрәш көннән-көн киңрәк җәелә бара. „Кызыл Ямбулат“ колхозы язгы чәчүгә хәзерлекне яхшы күрсәткечләр белән төгәлләде. 1939 нчы елгы уңыштан барлык кирәк фондларны аерып куйды. Шул исәптән 572 центнер чәчү орлыклары тазартылып куелды һәм аларга анализ ясалды. Моннан башка 400 центнердан страховой фонд оештырылды. Авыл хуҗалыгы коралларыннан 31 сабанга, 4 чәчү машинасына, 62 тырмага, 10 культиваторга һәм сбруйларга ремонт ясалды.

Колхоз председателе иптәш Гәрәев колхозның эше турында болай ди:

— 1939 нчы елда хезмәт дисциплинасын ныгытып, агротехника чараларын тулысынча куллану нәтиҗәсендә, без һәр гектардан уртача 10 центнер уңыш алдык. Һәр хезмәт көненә 4 килограмм бөртекле ашлык бүлдек. Безнең кайбер стахановчыларыбыз 250 шәр пот ашлык алдылар.

Без 1940 нчы елда гектардан 100 пот иген уңышы алу ярышына кушылдык. Бу ярышта җиңеп чыгу өчен тиешле чараларны күрәбез. Җир ашлау өчен 7,75 тонна минераль ашламалар ташып куйдык. Көл, кош тизәге һәм фекаль ашламаларын җыеп барабыз. 84 гектар мәйданда кар тоту чаралары уздырылды.

Колхозда агрономия техникасын өйрәнү буенча 4 түгәрәк эшли, анда 48 кеше системалы рәвештә занятиеләргә катнаша.

Безнең колхозда хәзер 37 стахановчы бар. Без шушы стахановчыларның эш методларын барлык эш тармакларында куллану белән гектардан 100 пот уңыш алу бурычын уңышлы үтәрбез.

(ТатТАСС).

КИМЕНДӘ 100 ПОТ

Үткән елны мин Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә булдым. Безнең Буденный исемендәге колхоз да (Юдино районы) анда экспонент булып катнашты. Күргәзмәдә „Орлык“ павильонын караугa һәм анда тупланган гаят бай тәҗрибәләрне өйрәнүгә бик нык игтибар бирдем.

Күргәзмәдән кайткач мин колхозчыларга алдынгы колхозларның югары иген уңышы алуга ничек ирешүләре турында сөйләдем. Безнең колхозыбыз да быел Сталинчыл югары иген уңышы алуга керешү өчен конкрет план төзеде һәм бу планны тормышка ашыра башлады.

Алдынгыларның югары иген уңышы алуга ничек ирешүләрен без хәзер бик яхшы беләбез. Барлык эш—агротехника чаралары комплексын үз вактында һәм дөрес итеп үткәрүдә.

Соңгы өч елда безнең Буденный исемендәге колхоз бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 14 центнер иген уңышы алды. Быел гектарыннан кимендә йөз пот алу өчен көрәш алып барабыз. Колхозда машиналарга ремонт ясау, орлык чистарту һәм ашламалар хәзерләү эше бик уңышлы бара.

Борисоглебск авыл халкы мине авыл советына депутат итеп сайлап, миңа гаят зур ышаныч күрсәттеләр. Мин хәзер Борисоглебск авыл советында председатель булып эшлим. 1940 нчы елда Борисоглебск авыл советына караган барлык колхозларда да югары иген уңышы алуга ирешү өчен бөтен көчемне биреп эшләрмен.

А. Тарасов.

„БЕРЕНЧЕ МАЙ“ КОЛХОЗЫНДА

Сарман районының Азалак авылы „Беренче Май“ колхозы үткән ел, һава шартларының бер кадәр начар булуына да карамастан, югары уңыш алды. Бодайның һәр гектарыннан 82 пот уңыш чыкты. Солы уңышы гектарына 102 пот булды.

Колхоз бу уңышны агротехника чараларын үз вактында дөрес үткәрү, җирле ашламалардан тулысынча файдалану нәтиҗәсендә ирешә.

Колхозчылар җирле мөмкинлекләрне исәпкә алганнан соң Калинин район алдынгыларының чакыруына кушылып, быел һәр гектардан 100 пот иген уңышы алу турында йөкләмә алдылар.

Колхозда язгы чәчү эшләре уңышлы бара.

Рәимев.

ГЕКТАРЫННАН 50—70 ЦЕНТНЕР УҢЫШ АЛУ ӨЧЕН

Калинин районының барлык колхозларында да даими звенолар оештыру тәмам булды. 100 гә якын звено үзләренә беркетелгән участкыларда 1940 нчы елда бөртекле культураларның һәр гектарыннан 50—70 центнер иген уңышы алуга ирешүне йөкләмә итеп алдылар.

Хәзер бу звенолар язгы чәчүгә ныклап хәзерләнәләр. Җирле ашламалар җыю буенча зур эш җәелдерелде. 500 центнер минерал ашлама кайтарту өчен Татнаркомземга заявка җибәрелде.

(ТатТАСС).

„ДИНАМО“ КОЛХОЗЫНЫҢ УҢЫШЛАРЫ

Кама Тамагы районының „Динамо“ колхозы язгы чәчүгә хәзерләнүдә шактый зур уңышларга ирешә. 24 нче декабрьдә бу колхоз чәчү инвентарьларына ремонт ясауны тулысынча төгәлләде. Аларны колхоз правлениесе акт белән кабул итте. Кирәк булган 200 капчык сатып алынды.

Агротехника чараларын үтәү һәм орлыкларны хәзерләү эшенә җитәкчелек итү, тәҗрибәле игенче—хата-лаборатория мөдире иптәш Маликовка тапшырылды. Хәзер колхозда 580 центнер орлык яхшы сыйфатка җиткерелеп куелды, 150 гектарда кар тоту үткәрелде, 2.000 йөктән артык тирес чыгарылды.

(ТатТАСС).

Хезмәт ияләре депутатларының жирле Советларына сайлауларның йомгаклары һәм халык арасында агитация-масса эшенең чираттагы бурычлары

Пропаганда һәм агитация работникларының өлкә киңәшмәсендә ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Долотказинның 1940 нчы ел, 5 нче гыйнварда ясаган докладыннан

Дөньяда иң демократик сайлау законы нигезендә—Сталин Конституциясе нигезендә — илебездә дәүләт властының барлык органнарын гаят зур яңадан төзү хезмәт ияләре депутатларының жирле Советларына сайлаулар белән тәгәлләнде. Бөтен ССР Союзындагы кебек үк, Татарстан республикасында да бу сайлаулар массаның югары политик активлыгы билгесе астында, яңа гүзәл җиңүгә ирешкән коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы билгесе астында үттеләр; алар хезмәт ияләренең Ленин—Сталин партиясе эшенә, коммунизм эшенә тайпылышсыз рәвештә чын күңелдән бирелгәнлегенең тагын бер ачык демонстрациясе булдылар 24 нче декабрьдә тавыш бирүдә 1.424.195 кеше яки Татарстан АССР дагы барлык сайлаучыларның гомуми санына карата 98,8 проценты катнашты; коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы кандидатларына 97,6 процент кеше үзләренең тавышларын бирделәр.

Жирле Советларга булган сайлаулар хезмәт ияләренең яңа катлауларын дәүләт эшенә тарттылар.

Эшчеләрдән, колхозчылардан, шәһәр һәм авыл интеллигенциясеннән сайланган депутатлар арасында партиясезләр 19.531 кеше (73,1 процент) һәм хатын-кызлар 8.634 кеше (32,3 процент).

Сайлаулар партиябезнең халыклар массасы белән какшамаслык элемтәдә булуын тагын һәм тагын бер тапкыр күрсәттеләр. Коммунистлар һәм партиясезләр Сталинчыл блок кандидатларына бердәм тавыш бирделәр.

Жирле Советларга сайлауларда коммунистлар һәм партиясезләр блогының гүзәл җиңүе социализмның гаят зур җиңүе булып, партиябезнең Ленин—Сталин милли политикасының тантанасы булып, коммунистлар һәм партиясезләр союзын тагын да ныгытуның күрсәткече булып тора,—бу союз Ватаныбыз куәтенең какшамаслык нигезе булып тора.

Сайлау кампаниясе вактында партия оешмалары халыкларның иң киң массалары арасында, халыкның барлык катлаулары арасында үзләренең күләмнәре ягыннан гаят зур булган агитация-пропаганда эше җәелдерделәр. Бу вакыт эчендә ун меңнәрчә яңа активистлар—җәмагат эшчеләре үсеп чыктылар. Сайлау комиссияләре составында гына да 125.368 кеше эшләде. 70.000 гә якын кеше агитатор, пропагандист һәм доверенный булып эшләде. Агитаторларның һәм доверенныйларның иң зур күпчелеге гаят зур энтузиазм белән эшләде.

Большевистик сүзләрнең байракларын алып баручы бу кешеләр турыдан-туры сайлау участокларында, сайлау округларында, ун йортлыкларда, аерым йортларда һәм квартираларда булып,—сайлаучыларга аларның гражданлык хокуклары һәм бурычлары турында, сайлауларның вакты, урны һәм тәртибе турында игтибар белән, ныклы һәм аңлаешлы рәвештә сөйләделәр, коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы кандидатлары өчен тырышып агитация алып бардылар, сайлаучыларны депутатлыкка кандидатларның биографияләре белән, аларның җәмагат һәм политик эшләре белән таныштырдылар. Агитаторларның һәм доверенныйларның тырышып эшләүләре нәтиҗәсендә большевистик турылык сүзе кешеләрнең йөрәкләренә үтеп керде һәм сайлаучыларның политик активлыгын тагын да югары күтәрде. Активистларның бу кадрлары—партиянең алтын фонды; аларны барлык чаралар белән сакларга һәм үстерергә кирәк.

Хезмәт ияләре арасында агитация-масса эшенең бик яхшы үрнәкләрен биргән күп кенә партоешмалар бар. Мәсәлән, Кайбыч районының Олы Урсак авылындагы башлангыч партоешманы күрсәтергә мөмкин. Монда агитколлектив 24 кешедән тора, шул исәптән коммунистлар 9 һәм комсомолецлар 6 кеше. Агитколлективның җитәкчесе ВКП(б) члены иптәш Җиһаншин агитаторлар белән регуляр рәвештә, биш көнгә бер тапкыр занятие үткәрде, ә агитаторлар сайлаучылар белән һәр биш көнгә бер тапкыр занятие үткәрделәр. Агитаторлардан тыш, һәрбер округга, нинди булса да сәбәпләр белән түгәрәк занятиеләренә йөри алмаучы кешеләр булган йортларда эшләү өчен актив беркетелде. Бу авылда барлык 23 округта да депутатлыкка кандидатларның сайлаучылар белән очрашулары, сайлаучыларның яхшы килүләре һәм актив катнашулары белән оешкан рәвештә үттеләр.

Партиянең күп кенә оешмалары агитация-масса эшен производство бурычлары белән оста рәвештә бергә куша белделәр һәм шуның белән еллык производство планнарының срогыннан элек үтәлүен тәэмин иттеләр. Мисаль өчен Казан Мехкомбинаты янындагы партия оешмасын алырга мөмкин. Агитация эшен производство бурычлары белән оста итеп бергә бәйләп алып бару нәтиҗәсендә комбинат, 1938 нче елга чагыштырганда хезмәтнең җитештерүчәнлеген 24 процентка арттырып һәм продукциянең үзенә төшкән бәясен 2,5 процентка киметеп, еллык планны 15 нче декабрьгә үтәде. Вахитов исемендәге жиркомбинат (2 нче декабрьгә), язу машиналары заводы, Кызыл Шәрык заводы, „Светоч“ фабрикасы, „Спартак“ комбинаты, күнгалантерея фабрикасы, Васильеводагы агач комбинаты һәм башкалар да еллык программаны срогыннан элек төгәлләделәр.

Хуҗалык-политик бурычларны үтәү буенча аерым авыл районнары да яхшы күрсәткечләр белән аерылып торалар. Бу—партия оешмалары массовый-политик эш белән производство мәсьәләләре арасында аерылышуга юл куймаган урыннарда булды. Мондый районнар исәбенә Әтнә, Ворошилов һәм башка күп кенә районнарны кертергә мөмкин. Хәзер монда Сталинград өлкәсе бригадирларының гектарыннан йөз пот иген уңышын җыеп алу өчен чакырулары тирәсендә зур массовый-политик эш алып барыла. Ул яңадан практик эшләр белән—кар тоту, кырга тирес чыгару, чәчүлек орлыкларны сортлау эшләре белән ныгытыла.

Мондый мисальләрне бик күп китерергә мөмкин. Алар партиянең барлык оешмалары өчен үрнәк булып хезмәт итәләр. Партиянең барлык оешмалары массовый-политик эшне нак менә агымдагы хуҗалык бурычлары белән бергә бәйләп алып барырга тиешләр.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар буенча сайлау кампаниясендә, бигрәк тә партия оешмалары булмаган урыннарда комсомол оешмаларына зур роль уйнарга туры килде. Республиканың бары тик 46 районыннан алынган мәгълүматларга караганда гына да, 10.142 комсомолец агитатор булып эшләде. Болардан тыш күп кенә комсомолецлар сайлау комиссияләре составында һәм доверенныйлар булып эшләделәр.

Сайлау кампаниясендә большевистик матбугат—безнең өлкә, район газеталарыбыз, күп тиражлы һәм стена газеталарыбыз зур роль уйнадылар, алар коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы кандидатлары өчен агитация алып бару белән бергә, республикабызда, шәһәрдә, районда һәм авылда социалистик төзелешнең казанышларын киң популярлаштерделәр, массаның иҗад инициативасын тупладылар, хуҗалык һәм культура бурычларын уңышлы хәл итү өчен предприятиеләрдә, совхозларда, МТС ларда һәм колхозларда үсеп баручы хезмәт күтәрелешен җәелдерделәр.

Узган елның август урталарыннан башлап, „Красная Татария“ газетасы хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларга хәзерлеккә багышланган 14 баш мәкалә, агитаторларга ярдәмгә күп кенә мәкаләләр басып чыгарды, шулай ук республикада һәм аның аерым шәһәрләрендә, районнарында һәм авылларында социалистик төзелешнең уңышлары турында берничә бит бирде.

„Кызыл Татарстан“ газетасы шул ук чор эчендә җирле Советларга сайлауларга карата 12 баш мәкалә басып чыгарды, агитаторларга ярдәмгә күп кенә мәкаләләр һәм консультацияләр урнаштырды, күп кенә битләр бирде. Өлкәдәге башка газеталарда да „Хӗрлӗ Ялав“, „Комсомолец Татарии“, „Яш Сталинчы“ газеталарында да шуларга ошашлы материаллар иглан ителде.

Сайлаулар кампаниясендә үзләренең бурычларын район матбугаты да яхшы башкарды. Үзләренең бөтен эшләрен жирле Советларга сайлауларның уңышлы чыгуына буйсындырган газеталар исәбенә, аерым алганда, Алабуга районының „Сталинский путь“ һәм „Сталин юлы“ газеталары, Минзәлә районының „Знамя Ленина“ газетасы, Чистай районының „Прикамская Коммуна“ газетасы, Бөгелмә районының „Колхозник“ газетасы, күп тиражлы газеталардан Серго Орджоникидзе исемендәге заводның „Орджоникидзовец“ газетасы, Ленин исемендәге заводның „Сталинец“ газетасы һәм башка күп тиражлы газеталарны кертергә мөмкин.

Жирле Советларга сайлауларга хәзерлектә, бигрәк тә кандидатлар өчен агитация алып баруда стена газеталары зур роль уйнадылар. Мәсәлән, Саба районында 280 номер стена газеталары, Кызыл Армия районында 436 номер, Әгерҗе районында 691 номер чыгарылды һәм башкалар.

Сайлауларга карата Татгосиздат гомуми тиражы 562.000 данәдән гыйбарәт булган рус һәм татар телендә 20 исемдә китаплар һәм брошюралар басып чыгарды, шулай ук 200.000 данәгә якын тираж белән плакатлар һәм лозунглар басып чыгарды.

Политик агитациянең шушы барлык куәтле средстволары сайлау кампаниясендә үзләренең күләмнәре ягыннан тиңдәшсез рәвештә кулланылдылар, сайлау кампаниясе коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогының яңа җиңүе белән төгәлләнде.

Хезмәт ияләре депутатларының жирле Советларына сайлауларга хәзерлек һәм сайлауларны үткәрү чорында партиянең Татарстан оешмасы гаят зур эш үткәрде. Ләкин шуның белән бергә зур кимчелекләр турында, аерым хәлләрдә агитация-масса эшендәге җидди ялгышлыклар турында әйтми китеп булмый, алар республиканың күп кенә районнарында булдылар.

ВКП(б) ның аерым райкомнары агитаторларны сайлап алуга чиктән тыш җавапсыз карадылар, өстән караш күрсәттеләр. Агитаторларны сайлап алу тәртибе турында ВКП(б) ның Үзәк Комитеты һәм Өлкә Комитетының күп тапкыр булган күрсәтмәләрен тупас рәвештә бозу фактлары булды. Партоешмалар булмаган авылларда агитаторларны ВКП(б) райкомы бюросында расламау гына түгел, хәтта райкомда алар белән бер кем дә танышмаган.

Яңа Писмән районында 452 агитатордан 325 агитатор декабрьгә кадәр башлангыч партоешмалар тарафыннан да, ВКП(б) райкомы тарафыннан да расланмаганнар иде. Чөнки райком башлангыч оешмаларга агитаторларны раслау хокукы бирмәгән. Ул гына да түгел, Карабаш авылы янындагы партоешма секретаре иптәш Хөснуллин положение буенча агитаторлар башлангыч партоешмалар тарафыннан расланырга тиеш дип күрсәтергә тырышкач, ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Панкратов һәм пропаганда-агитация бүлеге мөдире иптәш Радинов ана: „Безне өйрәтмәгез, без беләбез“ дип белдергәннәр.

Питрәч, Лаиш һәм кайбер башка районнарда да ВКП(б) райкомнары шулай ук агитаторларны расламаганнар. Җидди эшкә мондый җавапсыз караш кайбер урыннарда агитаторлар арасына чит элементларның үрмәләүләренә китерде.

Ютазы районында „Авангард“ колхозы янындагы башлангыч партоешма (Бәйрәкә авылы) агитколлективында элек зур җинаят өчен биш елга хөкем ителгән һәм срогын тутырып авылга кайткан кеше торган. Ә бит „Авангард“—Ютазы районында иң зур колхозлардан берсе. Монда 12 коммунист һәм 33 комсомолец, 42 укытучы бар, больница хезмәткәрләре, авыл советы һәм колхоз работниклары бар. Гомумән совет һәм колхоз активы, авыл интеллигенциясе җитәрлек санда бар, алар арасыннан иң яхшы, хәзерлекле, политик яктан ышанычлы, Ленин—Сталин партиясе эшенә турылыклы кешеләрне сайлап алырга мөмкин иде. Мондый актив, зурмы яки азмы күләмдә, һәр җирдә дә бар; безнең социалистик авылыбыз мондый кешеләргә бай.

Аерым авылларда агитаторлар кадрларының тикшерелмәгән кешеләр белән чүпләнүләре фактын бары тик безнең кайбер партоешмаларыбызның җавапсыз караулары һәм большевистик уяулыклары тупаслану белән генә аңлатырга мөмкин.

Мондый фактларның булуы шуны күрсәтә: тар-мар ителгән сыйныфларның калдыклары, троцкичы-бухаринчы һәм буржуаз милләтче бандитларның калдыклары һәм һәр төрле сектант элементлар, безгә дошман булган кешеләр—сайлаулар кампаниясендә безне пычыратырга маташачакларын, коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы кандидатларының дәрәҗәләрен төшерергә маташачакларын, Советларга үз кешеләрен кертергә, сайлаучыларның сайлауга килүләрен өзәргә маташачакларын партия оешмаларының кайбер җитәкчеләре кирәгенчә аңлап җиткермәгәннәр булса кирәк. Ә сайлау кампаниясе вактында дошманнарның контрреволюцион эшне активлаштырырга, колхозчылар арасына чит йогынтылар үткәрергә маташулары Кайбыч районында („Ирек“ колхозында, Ульяновко авылында) һәм Беренче Май районында („Кызыл Юл“ һәм „Алга“ колхозларында) һәм башка районнарда булды. Дөрес, бу маташулар уңышсыз чыктылар.

ВКП(б) ның кайбер райкомнары агитаторлар кадрларын сайлап алуга җавапсыз карау белән бергә, аларны тәрбияләү белән дә канәгатьләнерлек шөгыльләнмиләр. Яңа Писмән райкомы моңа ачык мисаль була ала.

Партиянең ике оешмасы (авыл советы һәм МТС янында) һәм комсомолның өч оешмасы булган Иске Писмән авылында агитаторларга авыл советы җитәкчелек итә. Авыл советы председателе иптәш Фәттахов агитаторларны үзе сайлап алган, авыл советы пленумына аларның отчетларын куйган, аларның эшенә учетны да ул алып барган. Анда хәтта шундый вакыйга дә булган: агитаторлар составы тулы булмаган урта мәктәпнең педагогия советы утырышында расланган... Партия оешмалары „катнашмаучылык позициясе“ алганнар. Ә райком? Ул, үз чиратында, алардан берниндн дә җаваплылык таләп итмәгән, агитколлективка оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире иптәш Кузнецов җитәкчелек итә дип исәпләгән, чынлыкта исә иптәш Кузнецов октябрь башыннан бирле Иске Писмән авылында булмаган. Яңа Писмән районында күп кенә агитколлективлар яки бөтенләй эшләмәгәннәр, яки бик кызганыч хәлдә яшәгәннәр.

Бөтен бәлә шунда ки, ВКП(б) ның Яңа Писмән райкомы агитация-масса эшенең торышы өчен җаваплылыкны партиянең башлангыч оешмалары өстеннән алып ташлаган, аны тулысы белән агитколлективларның җитәкчеләренә йөкләгән, аларның күпчелеге—район үзәге работниклары. Мәсәлән, Яңа Писмән авыл советы янында партиянең 12 кешелек башлангыч оешмасы бар. Ләкин райком 5 нче ноябрьдә сайлауларга хәзерлекнең барышы турында башлангыч партоешма секратаре докладын тыңламыйча, агитколлектив җитәкчесе иптәш Неклюдов (райплан председателе) докладын тыңлаган. 1939 нчы елны ВКП(б) ның Яңа Писмән райкомы бюро утырышларында уннан артык агитколлектив җитәкчеләренең докладларын тыңлаган (сүз уңае белән әйтергә кирәк, алардан да чынлыкта җаваплылык таләп итмәгән), ләкин башлангыч партоешма секретареның докладын бер тапкыр да тыңламаган.

Норлат, Питрәч, Тымытык районнарында һәм республиканың кайбер башка районнарында да агитаторларны тәрбияләү эше шундый ук хәлдә.

Кайбер район газеталары да сайлау кампаниясенең гаят зур бурычлары югарылыгында булмадылар. Кайбер редакторлар бу өлкәдә чиктән тыш җавапсызлык күрсәттеләр. Мәсәлән, „Крепим колхозы“ (Арча районы) һәм „Большевистский путь“ (Лаиш районы) газеталарының редакторлары сайлауларга хәзерлек чорында оперативлыкны көчәйтмәделәр генә түгел, киресенчә, начаррак эшләделәр. „Большевистский путь“ газетасы айга 10 тапкыр урнына 4—5 тапкыр гына чыкты; „Крепим колхозы“ газетасының да чыгуы кимеде. Бу газеталар битләренең 70—80 проценты гадәттә рәсми материаллар белән тулган, агитация эше һәм сайлауларга хәзерлекнең оештыру-техника мәсьәләләре исә өченче дәрәҗәдәге урынга куелганнар.

Партия оешмалары барлык бу җидди кимчелекләрне искә алырга, аларны киләчәктә кабатламаска тиешләр. Шуның белән бергә, сайлаулардан соң массовый-агитация эшләрен аз гына да йомшартырга ярамаганлыкка партия оешмаларының һәм партия җитәкчеләренең игтибарын юнәлдерергә кирәк. Җанлы һәм ышандырырлык большевистик агитациянең гүзәл үрнәкләрен күрсәткән партияле һәм партиясез агитаторларның гаят зур активыннан киләчәктә дә файдаланырга кирәк.

Ләкин партиянең кайбер оешмаларында хәзер үк инде, жирле Советларга сайлаулардан соң берничә генә көн үтү белән үк, агитация эшен, бигрәк тә хезмәт ияләренең тору урыннарында, йомшату омтылышлары барлыгы турында ВКП(б) Өлкә Комитетында сигналлар бар.

Агитация эшен мондый йомшартырга маташуларны, агитациягә кампания рәвешендә карауны кискен рәвештә бетерергә кирәк. Агитация эше предприятиеләрдә дә, учреждениеләрдә дә, колхозларда да, шулай ук хезмәт ияләренең тору урыннарында да планлы, системалы һәм көндәлек рәвештә алып барылырга тиеш. Агитация-пропаганда эшендә сайлау кампаниясе чорында партия оешмалары ирешкән дәрәҗәне беркетеп кенә калдырмыйча, аны тагын да күтәрергә һәм төп игтибарны агитациянең сыйфатына һәм эчтәлегенә юнәлдерергә кирәк. Моның өчен партия оешмаларының җитәкчеләре агитаторлар кадрларын яхшы белергә һәм аларны әледән-әле тикшереп торырга тиешләр. Бары тик политик яктан тикшерелгән, идея ягыннан коралланган кешеләр генә, халык дошманнарына карата уяу һәм килешмәүчән кешеләр генә, Ленин—Сталин партиясе эшенә ахрынача чын күңелдән бирелгән кешеләр генә чын большевистик агитаторлар була алалар.

Партия оешмаларының бурычы—сайлау кампаниясе чорында эшләгән барлык агитаторларны учетка алудан, аларны агитколлективларга берләштерүдән һәм бу кадрларны кампания төсендә түгел, бәлки көндәлек эш тәртибендә тагын бер тапкыр җентекләп тикшерүдән, бу эшкә игтибарсыз караучылардан азат итүдән, яңа үсеп чыккан партияле һәм партиясез большевиклар активы исәбенә агитколлективларны тулыландырудан гыйбарәт. Шуның белән бергә, агитация эшенә совет интеллигенциясе вәкилләрен тартуга аеруча игтибар бирергә кирәк. Барлык агитаторлар башлангыч партоешмаларның бюро утырышларында, ә алар булмаган урыннарда ВКП(б) райкомнарының бюро утырышларында расланырга тиеш.

Агитколлективларга җитәкчелек итүне—квалификацияле агитаторлар кадрларын хәзерләргә, үстерергә, тәрбияләргә сәләтле булган иң тәҗрибәле иптәшләргә тапшырырга кирәк.

Агитколлектив җитәкчеләренә һәм барлык агитаторларга системалы рәвештә ярдәм булдыруны тәэмин итәргә кирәк; агитколлектив җитәкчеләре өчен—айга кимендә бер тапкыр һәм барлык агитаторлар өчен—декадага кимендә бер тапкыр махсус занятиеләр үткәрергә кирәк. Шулай ук агитация эшенең тәҗрибәләрен уртаклашу өчен периодик киңәшмәләр үткәрергә кирәк. Монда кайбер партоешмалар тарафыннан ясалган җидди кимчелекнең—агитколлектив занятиеләрен эш тәҗрибәсен уртаклашу киңәшмәләре белән алмаштыруның кабатлануына юл куймаска кирәк. Билгеле, халыкара хәл һәм башка аерым теоретик мәсьәләләр буенча атитаторлар өчен лекция яки доклад хәзерләүгә һәм укуга караганда мондый киңәшмәләрне үткәрү җиңелрәк.

Бу ялгышлыкны агитколлектив җитәкчеләре генә түгел, бәлки агитколлектив җитәкчеләре белән занятиеләр үткәрергә тиеш булган иптәшләр дә эшлиләр. Мин ВКП(б) райкомнары секретарьларын күздә тотам. Сүз уңае белән әйтергә кирәк, алар бу җидди эшне һәр вакытта да үз өсләренә алмыйлар, бәлки башкаларга тапшыралар.

Агитколлективларның занятиеләрендә агитаторларга үзлекләреннән докладлар, беседалар, кычкырып укулар хәзерләргә мөмкинлек бирерлек тәртипне урнаштырырга кирәк. Агитаторларның идея-политик дәрәҗәсен күтәрергә кирәк. Моның өчен һәрбер занятиедә аларга хезмәт ияләре арасында иң якын вакыт эчендә аңлатырга кирәк булачак мәсьәләләр буенча лекцияләр һәм докладлар укырга кирәк. Үз чиратында, агитколлектив җитәкчеләре өчен дә шулай ук тиешле лекцияләр яки докладлар укырга һәм шуның белән аларга агитколлективларда занятиеләр үткәрүдә системалы рәвештә ярдәм күрсәтергә кирәк.

Агитколлектив занятиеләренең планнары пропаганда һәм агитация бүлекләрендә, ә докладларның темалары агитколлектив җитәкчеләренең семинарларында, ВКП(б) райкомнарының бюро утырышларында каралырга тиеш.

Партия кабинетлары агитколлектив җитәкчеләренә һәм барлык агитаторларга ярдәм оештыруда зур эш башкарырга тиешләр. Парткабинетларның мөдирләре үзләренең пропагандистларга ярдәм итү бурычларын аңладылар, ә менә агитаторларга ярдәм итүне алар әле һаман да чынлап оештырмыйлар. Бу аларның эшендә сайлау кампаниясе вактында да зур җитешсезлек булды. Бу җитешсезлекне бетерергә кирәк.

Райпарткабинетларда да, шулай ук предприятиеләрдә, колхозларда, учреждениеләрдә дә групповой һәм индивидуаль консультацияләр оештыру, агитаторлар өчен әдәбият, белешмә материал сайлап алу, алар белән политик карталарны тикшерү, ярдәмче пособиеләр белән, Татарстан республикасы, районнар, колхозлар тормышыннан җирле материал белән тәэмин итү—партия кабинетларының көндәлек практикасына керергә тиеш.

Ләкин агитаторларны укыту, аларга инструктаж ясау белән генә эш бетми әле. Аларның эш сыйфатын системалы рәвештә тикшерергә кирәк. Агитаторның, фактлардан һәм саннардан файдаланып, коммунизм төзелеше турында, безнең уңышларыбыз һәм бурычларыбыз турында аудиториягә ничек итеп кызыклы һәм оста итеп сөйләвен тикшерергә һәм белергә кирәк. Агитаторның ялгышларын һәм кимчелекләрен вактында күрергә, төзәтергә һәм кисәтергә кирәк.

Кызганычка каршы, сайлау кампаниясе чорында, партиянең кайбер оешмалары, еш кына зур саннар артыннан куып, йөзләрчә агитаторларны сайлау участкыларына җибәреп тә, аларның эш сыйфатын җитәрлек күзәтмәделәр, түгәрәкләрдә занятиеләргә, беседаларга, кычкырып укуларга аларның җентекләп хәзерләнүләрен тикшермәделәр. Хәлбуки, иптәш Ленин күрсәтмәләрен һәр вакыт истә тотып бу нәрсәләргә аеруча игтибар бирергә кирәк иде. Ленин болай диде: „һәрбер пропагандистның һәм һәрбер агитаторның осталыгы аудиториягә иң яхшы йогынты ясаудан, маглүм хәкыйкатьне аның өчен мөмкин кадәр ышандырырлыгырак, мөмкин кадәр җиңел аңлашылырлык, мөмкин кадәр ачыграк һәм нык истә калырлыгырак итүдән тора да“. (XV нче том, 288 нче бит).

Сайлау кампаниясе чорында предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, колхозларда, шулай ук хезмәт ияләренең тору урыннары буенча йортлар группаларында, аерым йортларда, гомуми торакларда төзелгән түгәрәкләрнең киң челтәрен агымдагы политика түгәрәкләре төсендә, әлбәттә, саклап калырга кирәк, алар декадага кимендә бер тапкыр занятие үткәрергә тиешләр һәм аларда халыкара хәл һәм илебезнең эчке тормышы мәсьәләләре, партия һәм хөкүмәт карарлары һәм башкалар тыңлаучыларга аңлатылырга тиеш. Түгәрәккә даими агитатор беркетергә кирәк. Ул, түгәрәктә өйрәнүче һәрбер иптәшне белергә, кем белән һәм ничек

(Ахры 3 нче биттә).

Иптәш Долотказин докладының ахры

(Башы 2 нче биттә)

эшләргә кирәклекне, кемгә ничек якын килергә кирәклекне белергә тиеш. Сайлау кампаниясе тәҗрибәсеннән без, бу түгәрәкләрнең әһәмияте никадәр зур икәнлекне беләбез. Анда шәһәрдәге һәм авылдагы чираттагы хуҗалык-политик чараларны үткәрүдә гаять зур файда китерергә сәләтле булган меңнәрчә һәм ун меңнәрчә партиясез активистлар хәзерләнәләр. Анда большевистик агитаторларның яңадан-яңа кадрлары туа.

Шуның белән бергә, сайлау кампаниясе вактында эшләгән агитпунктларны бетерүгә юл куярга ярамаганлыкны әйтергә кирәк. Верховный Советларга сайлаулардан соң мондый фактлар булды. **Агитпунктлар халык арасында массовый-политик эшнең даими чын үзәкләре булырга тиешләр.**

Аларда хезмәт ияләренә лекцияләр, докладлар тыңларга, кычкырып укулар оештырырга, радио тыңларга, күп төрле мәсьәләләр буенча беседаларда катнашырга, консультацияләр алырга мөмкинлек бирергә кирәк. Агитпунктлар партиянең һәм хөкүмәтнең иң әһәмиятле карарларын, халыкара хәл мәсьәләләрен хезмәт ияләре арасында аңлатуда агитаторларга, беседачыларга һәм кычкырып укучыларга даими ярдәм күрсәтергә тиешләр. Агитпунктларны әдәбият белән, пособиеләр белән, квалификацияле мөдирләр белән, агитаторларның, беседачыларның һәм кычкырып укучыларның даими активы белән тәэмин итү буенча хәзер үк чаралар күрергә кирәк. Шуның белән бергә, барлык политик агарту учреждениеләренең—клубларның, уку өйләренең, кызыл почмакларның эшен кискен рәвештә яхшырту чараларын күрергә кирәк; политик эштә агитпунктларга ярдәм итәргә һәм аларның үтәлешенә тиешле контроль урнаштырырга кирәк. Якын вакыт эчендә политик агарту учреждениеләре работникларының (культура йортлары мөдирләренең, колхоз клублары һәм уку өйләре мөдирләренең, агитпункт, кызыл почмак һәм китапханә мөдирләренең) район киңәшмәләрен үткәрергә, аларда җирле Советларга сайлауларның йомгаклары турында һәм халык арасында массовый-политик эшне җәелдерүдә агитпунктларның һәм барлык политик агарту учреждениеләренең алдагы бурычлары турында докладлар куелырга тиеш. Агитпунктларның эшен туктатырга омтылуларны кискен рәвештә бетерергә кирәк.

Киләчәктә дә массовый-политик эшнең төп эчтәлеге хезмәт ияләре массасын партиябезнең XVIII нче съездының тарихи карарларын белү белән коралландырудан һәм бу карарларны үтәүгә аларны туплаудан, халыкара политика мәсьәләләрен аңлатудан гыйбарәт булырга тиеш.

Һәрбер совет гражданины иптәш Сталин күрсәтмәсен нык үзләштерергә тиеш: „Сугыш һөҗүме куркынычы каршында безнең бөтен халкыбызны мобилизация хәзерлегендә тотарга кирәк, бер нинди дә „очраклылык" һәм безнең тышкы дошманнарыбызның бер нинди дә фокуслары безне көтелмәгән хәл алдында калдырырлык булмасын".

Массовый-политик эшне җәелдерү белән без хезмәт ияләренең революцион уяулыгын тагын да күтәрүне, аларны халык дошманнарына карата дошманлык рухында, үзләренең социалистик ватаннарына карата, большевистик партиягә карата, сөекле юлбашчыбыз һәм остазыбыз иптәш Сталинга карата чын күңелдән бирелгәнлек рухында тәрбияләүне тәэмин итәргә тиешбез.

Партия оешмалары агитация-масса эшен производство бурычлары белән бергә бәйләргә, социалистик төзелешнең яңа җиңүләре өчен хезмәт ияләренең көрәшенә җитәкчелек итәргә, промышленностьта һәм авыл хуҗалыгында стахановчылык хәрәкәтен киң җәелдерергә тиешләр.

Иптәш Сталин безне болай дип өйрәтә:

„Политиканы хуҗалыктан аерырга ярамый. Без, политикадан китә алмаган шикелле, хуҗалыктан да китә алмыйбыз. Өйрәнергә уңайлы булсын өчен, кешеләр гадәттә, хуҗалык мәсьәләләрен политика мәсьәләләреннән методология ягыннан аералар. Ләкин бу тик методология ягыннан, ясалма рәвештә, өйрәнергә уңайлы булсын өчен генә эшләнә. Тормышта киресенчә, практикада политика һәм хуҗалык бер-берсеннән аерылгысыз. Алар бергә яшиләр һәм бергә хәрәкәт итәләр. Һәм, безнең практик эштә хуҗалыкны политикадан аерырга, политик эшне кечерәйтү хакына хуҗалык эшен көчәйтергә яки, киресенчә, хуҗалык эшен кечерәйтү хакына политик эшне көчәйтергә уйлаучы кеше,—ул һич шиксез тупикка эләгәчәк".

Иптәш Сталинның бу күрсәтмәләрен партия оешмалары бөтен массовый политик эшнең нигезенә салырга тиешләр.

Агитация-масса эшенең нәтиҗәләрен ныгытуда большевистик матбугат гаять зур роль уйный. Безнең өлкә, район газеталарыбыз һәм күп тиражлы газеталарыбыз халык арасында агитация-масса эшенең барышын, электәгечә киң яктыртырга, производство планнарын уңышлы үтәүгә тупларга, хезмәтнең югары җитештерүчәнлеге өчен, Сталинчыл иген уңышы өчен, терлекчелекнең күтәрелеше өчен, 1940 нчы елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә колхозларның катнашулары хокукы өчен көрәшкә массаны тупларга тиешләр.

Һәрбер газетаның бурычы—Сталинград өлкәсе бригадирларының һәм республикабызның Калинин районы авыл хуҗалыгы алдынгыларының гектардан 100 пот иген уңышы алу турындагы мөрәҗәгатләренә кушылудан, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашучыларның тәҗрибәләрен барлык чаралар белән популярлаштырудан гыйбарәт.

Иптәшләр! Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар нәтиҗәсендә ун меңнәрчә алдынгы яңа кешеләр, Ленин—Сталин типындагы дәүләт эшлеклеләре дәрәҗәсенә кадәр үскән партияле һәм партиясез большевиклар дәүләтне идарә итүгә килделәр. Партиянең барлык оешмаларының бурычы—көндәлек эштә һәрбер депутатны тәрбияләүгә һәм аны тагын да үстерүгә аеруча игтибар бирүдән, аңа идея-политик дәрәҗәсен күтәрүдә һәм партиянең XVIII нче съезды һәм бөек Сталин тарафыннан куелган җаваплы дәүләт бурычларын үтәүдә практик ярдәм итүдән гыйбарәт. (Көчле кул чабулар).

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар коммунизм тантанасына бару юлында илебездә гаять зур яңа җиңү булды. Алар совет халкының мораль-политик бердәмлеген тагын бер тапкыр яңа көч белән күрсәттеләр. Бу бердәмлекне тагын да ныгытырга, социалистик җәмгыятнең хезмәтчел халыклары арасында агитация-масса эшен барлык чаралар белән көчәйтергә кирәк. (Кул чабулар).

НАРКОМ ПРИКАЗЫН ТУЛЫ ҮТӘРГӘ

Тимер юл транспортының кышкы шартларда эшли башлавына айдан артык вакыт үтте. Бу чор эчендә Казан тимер юлы бүлекләренең, станция һәм разъездларның кышка хәзерлекләре практик эштә сыналды. Кышкы шартларда эшләүнең беренче йомгаклары кайбер бүлекләрнең кышка чиктән тыш начар хәзерләнүләре, шуның нәтиҗәсендә соңгы вакытларда йөк ташуларның акрынаюы, дәүләт планының үтәлеше ачыктан-ачык өзелүе турында сөйлиләр.

Мисаль өчен Әгерҗе бүлеген алыйк. Бу бүлек хәзерге вакытта Казан тимер юлында артта калучы участкыларның берсе. Әгерҗе станциясе аеруча начар эшли. Монда хәзер дистәләрчә поезд составлары маршрут буенча озатылу өчен 15—20 көн буена чират көтеп яталар. Поездларның соңга калып җибәрелүләре гадәт булып әверелгән.

Ни өчен соң мондый таркалганлык, борыла алмаучылык хөкем сөрә? Чөнки паровозлар депосы һәм станция җитәкчеләре кышка хәзерлексез керделәр. Поезд составларын маршрут буенча озату өчен төзек булмаган паровозлар бирелә. Шуның аркасында паровозлар 30—40 километр юл үткәннән соң, сафтан чыгалар, яңадан ремонтка керәләр. Ә бу хәл исә поездлар хәрәкәтен тарката, йөк ташу планының үтәлешен өзә.

Кадрларны тәрбияләү, аларны эшкә өйрәтү, стахановчылык хәрәкәтенә җитәкчелек Әгерҗедә һич канәгатьләнерлек түгел. Бүлекнең мактаулы папавинчы машинистлары Захаров, Болгушев, Шкатов, Верегин, Парыгин һәм иң яхшы составительләр Мусин, Жереб иптәшләрнең гүзәл эш тәҗрибәләрен уртаклашу эшен оештырмауны, Октябрь бәйрәме алдында күтәрелгән социалистик ярышның соңгы вакытларда йомшарып китүен нәрсә белән аңлатырга мөмкин соң? Станция начальнигы Галочкин, партоешма секретаре Даутов эшкә оператив җитәкчелек итүдән читләшкәннәр.

Техник эксплуатация кагыйдәләрен өйрәнү эше Әгерҗе станциясендә бик йомшак оештырылган. Станциянең байтак кына эшчеләре кышкы шартларда эшләү тәртибе буенча элементар кагыйдәләрне дә белмиләр. Техник укулар оештырылмаган. Аварияләрнең һәм бракның Әгерҗе станциясендә кимемәвенең сәбәбен әнә шуның белән генә аңлатырга мөмкин.

Сталинчыл нарком иптәш Каганович тимер юл транспортының кышкы шартларда эшләве турындагы приказларында конкрет эш программасын билгеләде. Ләкин бу приказлар Әгерҗедә һәрбер тимер юлчы аңына җиткерелмәгән. Бу өлкәдәге массовый эш нарком приказын бер тапкыр гомуми җыелышта укып чыгу белән чикләнелгән. Үтәлешне тикшерү эше белән һич кем шөгыльләнми. Эштә брак һәм авария ясаучыларга карата үз вактында чара күрелми. Теге яки бу авариянең сәбәпләре тикшерелми.

Бу аяныч хәл якын арада бетерелергә, Әгерҗе станциясенең һәм паровозлар депосының эше якын арада сәламәтләндерелергә тиеш. Станция һәм депо коллективларын нарком приказын тайпылышсыз үтәү тирәсенә тупларга кирәк.

Әгерҗе станциясе начальнигы Галочкин эштә җавапсызлык, башбаштаклык күрсәтүе һәм нарком приказын үтәмәве өчен эшеннән алынды. Бу факттан станциянең һәм шулай ук депоның барлык җитәкчеләре үзләренә тиешле сабак алырга, эшне якын арада большевикларча оештыру өчен барлык чараларны күрергә тиешләр.

Кәримов.

Казан тимер юлының политбүлек инструкторы.

ХЕЗМӘТ ДИСЦИПЛИНАСЫ НЫГЫЙ

Ленин исемендәге күн заводының дуплау цехы иң катлаулы цехларның берсе. Галимҗан иптәш Хуҗиҗанов шушы цехта 6 елдан бирле эшли инде. Ул соңгы 3 ел буена барабаннар аппаратында бригадир булып эшли. Аның бригадасы эштә һәр вакыт үрнәк күрсәтә. Бригада да 1939 нчы елда хезмәт дисциплинасы аеруча нығыды. Эшкә соңга калып килү, яки иртә китү кебек фактлар тәмам бетерелде диярлек. Эштә ныклы тәртип булдыру һәм эш сәгатеннән тулы файдалану нәтиҗәсендә бригада планны ай саен арттырып үтәүгә ирешә.

Иптәш Хуҗиҗанов бригаданың эше турында болай ди:

— Бригадабызда элек кайбер кешеләр тарафыннан хезмәт дисциплинасын бозу фактлары бар иде. Мәсәлән, Смирнов, Усманов һәм Маннапов иптәшләр хезмәт дисциплинасын еш бозып килделәр. Без мондый хәлне бик тиз бетердек. Хәзер Смирнов, Усманов һәм Маннапов иптәшләр эш сәгатеннән дөрес һәм тулы файдаланалар, алар сменага бер ярым, хәтта икешәр норма бирүгә кадәр ирештеләр. Аларның хезмәт хаклары да айдан-айга арта. Без цехта бригадалар һәм аерым эшчеләр арасында эштә ныклы тәртип булдыру турында киңәшмәләр һәм беседалар үткәрәбез. Минем бригадада эшләүче яшь эшчеләрдән Цедриский, Матвеевский һәм Әхмәтҗанов иптәшләр белән еш кына беседалар үткәрәм.

Бригада хәзер 8 урнына 10 барабанда эшли. Смена саен диярлек икешәр һәм өчәр норма бирәбез. Октябрь һәм ноябрь айларында чималга шактый зур экономия ясалды.

Хуҗиҗанов бригадасы стахановчы бригада булу өчен көрәшә.

Һ. Рәхмәтуллина.

ТӨЗҮЧЕ СТАХАНОВЧЫЛАРНЫҢ УҢЫШЛАРЫ

14 нче номерлы трестның төзүчеләр коллективы 1940 нчы елда яңа җиңүләр яулап алу өчен көрәшә.

Район советы депутаты—стахановчы токарь Миңгалиев, электросварщик Гиниятуллин иптәшләр көнлек норманы 200 процент итеп үтиләр. Слесарьлардан иптәш Булыгин бригадасы көнлек заданиене 280 процент, котельщиклардан Воронцов һәм Королев иптәшләр җитәкчелек итә торган бригадалар көнлек заданиене 210—215 процент итеп үтиләр.

„СЕДОВ" хәрәкәтенең картасы

Алдынгы фәнгә кыйммәтле хәзинә

Е. К. ФЕДОРОВ

Советлар Союзы Герое

1937 нче елның октябрендә Новосибирск атауларыннан көнбатышта өч карабны: „Седов"ны, „Малыгин"ны һәм „Садко"ны бозлар агымы алып киткән иде. Бозлар агымы башта аларны төньякка, аннары төньяк-көнчыгышка һәм төньяк-көнбатышка таба алып китте. Нансен экспедициясе карабы—атаклы „Фрам"да үзенең бозлар агымы белән хәрәкәтен шул ук район тирәсендәрәк башлаган иде. Боз хәрәкәтеннән файдаланып, ул Боз океанының үзәк өлешенә, Котыпка үтеп чыгарга омтылган иде. Ләкин хәрәкәттәге боз „Фрам"ны котып бассейнының кырый зонасы буйлап алып китте. Нансен үзенең теләгенә ирешә алмады. Шуңа да карамастан, аның экспедициясе Боз океанының табигате турында кыйммәтле маглүматлар туплады. Алар озак вакытлар буе фән файдаланып килгән бердәнбер маглүматлар булдылар.

Нансеннан соң Котыпка боз өстеннән, самолетта һәм дирижабльдә берничә экспедиция үткәрелде. Ләкин аларның телгә алырлык фәнни әһәмиятләре булмады һәм була да алмады. Чөнки самолетта очканда яисә боз өстеннән барганда үзең белән күпмегә булса да озаграк вакытка җитәрлек азык һәм күзәтүләр өчен фәнни приборлар алып барырга мөмкин түгел. Хәрәкәттәге совет „Төньяк котып" экспедициясенең шактый куәтле техникасы бар иде. Без үз хәрәкәтебезнең башлангыч ноктасы итеп Төньяк котыпны сайлап алдык һәм бик күп төрле фәнни тикшерүләр өчен җиһазлар һәм кирәк-яраклар төягән куәтле совет самолетлары безне шунда илтеп куйдылар. Төньяк котыптан Гренландия диңгезенә хәрәкәт вактында без күп сандагы фәнни тикшерүләр үткәрә алдык. Хәрәкәттәге „Седов"—„Фрам"нан һәм „Төньяк котып"тан кала Үзәк Арктикага барып җитә алган хәрәкәттәге өченче фәнни тикшерү экспедициясе булды. „Фрам" һәм совет карабы үзләренең хәрәкәтләрен башлаган район бер үк булуга карамастан, бу судноларның хәрәкәтләре төрлечә булды. Бозлар хәрәкәте „Седов"ны башта төньяк-көнчыгышка алып китте һәм шуңа күрә дә Новосибирск атаулары меридианыннан Шпицберген меридианына кадәр Нансен „Фрамы" барган юлдан шактый төньяктарак барды.

Хәрәкәт вактында седовчылар хәрәкәттәге боз өстендә без үткәргән тикшерүләр шикеллерәк тикшерүләр алып бардылар. Системалы рәвештә метеорология күзәтүләре алып барылды, диңгез тирәнлекләре үлчәнде, төрле гидрология тикшерүләре, төрле тирәнлектә суның агымнарын, температурасын һәм химик составын үлчәү, авырлык көчен үлчәү, магнит көчен үлчәү һәм башкалар үткәрелде. Седовчылар тарафыннан еш үткәрелгән төгәл астрономия күзәтүләре карабның юлын һәр яклап күзәтеп барырга, аның хәрәкәтен метеорологик үзгәрешләр (беренче чиратта җил) белән чагыштырырга, Төньяк боз океанының бу районында бозның хәрәкәт законнары нинди икәнлекне белергә мөмкинлек бирәләр. Боз хәрәкәте законнарын белү Котып диңгезе юлы трассасында судноларның йөртүне уңышлы рәвештә алга җибәрүдә зур роль уйный. Бозларның урнашуларына җилнең нинди йогынты ясавын белгәч, шулай ук җил йогынтысы белән бозлар массасының кая таба һәм нинди тизлек белән хәрәкәт итүен белгәч, без Төньяк диңгез юлы үтә торган төньяк диңгезләрнең бозлы икәнлеген ышанып әйтә алабыз. Нансен „фрамы" да, „Төньяк котып" станциясе дә, „Седов" та бозның хәрәкәтенә анализ ясау өчен гадәттән тыш кыйммәтле һәм кызыклы материал бирәләр.

Төньяк котыпка экспедициягә киткән вакытта боз өстендә котыптан кайсы якка һәм нинди тизлек белән хәрәкәт итәчәгебез турындагы мәсьәлә, билгеле, безне кызыксындырды. Бозның хәрәкәте турында элекке тикшерүләр нигезендә китереп чыгарырга мөмкин булган нәтиҗәләрнең дөрес түгеллеге практикада күренде. Безнең боз без уйлаганга караганда тизрәк хәрәкәт итте. Бу хәл гомумән соңгы елларда Боз океанында хәрәкәт тизләнгән дигән фикергә китерде. Ләкин моны расларга мөмкин түгел иде. Чөнки „Төньяк котып" станциясе хәрәкәт иткән районда моннан элек хәрәкәт итеп күзәтүләр алып барылганы юк иде. Гаять әһәмиятле бу мәсьәләне ачыкландыруга „Седов" бик зур ярдәм итте.

Кайбер урыннарда „Седов"ның хәрәкәте элек „Фрам" хәрәкәт иткән районга якын килә. Без һәр ике судноның да хәрәкәтен чагыштыра алабыз. Менә шунда инде хәрәкәтнең соңгы вакытта тизләнгәнлеге турындагы караш тулысынча дөрес булып чыга. „Фрам" үткәнгә караганда күп ераграк юлны „Седов" кыскарак вакытта үтте. Котып бассейнында боз тизрәк хәрәкәт итә, димәк, Арктикада һава әйләнеше көчәйгән, Арктика белән урта киңлекләр арасында һава массивының алмашынып торуы тагын да тизләнгән. Соңгы 10 ел эчендә Арктиканың җылына төшүе шушы фактка бәйләнгән.

Седовчыларның күзәтүләре Арктикада магнит элементларының хәрәкәте турында да, җир шарында һәр җирдә бара торган җир магнитизмы көчләренең юнәлеше әкрен генә, аз-азлап кына үзгәрү турында да бик кызыклы маглүматлар бирделәр. „Седов" ның һәм „Фрам" ның хәрәкәтләре бер-берсенә якынлашкан районнарда бу караблар тарафыннан үткәрелгән магнит үлчәүләрен чагыштырып, без гадәттән тыш кызыклы нәтиҗәләр ясый алабыз. „Седов" та үткәрелгән тикшерүләр безгә магнит картасы төзәргә, һаваның режимын белергә, гидрология режимын белергә мөмкинлек бирәләр. Болар барсы да Котып диңгезе юлы үтә торган диңгезләр турындагы белемнәребезнең тагын да төгәлрәк, тагын да тикшерелгәнрәк булуына китерәләр.

„Седов" экипажының күзәтүләре безгә котып бассейнында чын авырлык көчен билгеләргә мөмкинлек бирә. „Седов" тагы күзәтүләр, бу өлкәдә „Фрам" да алып барылган күзәтүләрдән күп киңрәк һәм төгәлрәк. Седовчыларның күзәтү материаллары материкка тапшырылгач һәм эшкәртелгәч күп кенә бик әһәмиятле башка яңалыклар да килеп чыгачак.

Карабның героик экипажы үзенең эшен бик кыен һәм куркынычлы шартларда алып барды. Боз карабка күп тапкырлар җидди куркынычлар тудырды. Көчле боз өемнәре хәрәкәтенең судноның корпусын тишүе мөмкин иде. Седовчылар монда һәр вакыт хәзер тордылар. Алар азык запасын, кирәк-яракларны, күчмә радиостанцияне һәр бер моментта боз өстенә күчерерлек хәлдә тоттылар. Күп сандагы фәнни күзәтүләрне үтәү өчен экипажның барлык членнарына авыр эш башкарырга туры килде. Мәсәлән, диңгез тирәнлекләрен үлчәү өчен, һәр төрле коралларны океанның төбенә кадәр төшерү мөмкин булсын өчен, аларга урында корыч чыбыктан аркан хәзерләргә туры килде.

Седовчыларның ныклыгын һичбер төрле кыенлыклар җимерә алмады. Үзләренең эшләрен бөтен совет Ватанының күзәтеп торуын белеп, үзләренең эшләренә партиянең, хөкүмәтнең һәм иптәш Сталинның үзенең гаять зур игтибар бирүләрен белеп, алар илнең ышанычын аклау өчен, үзләренең зур һәм кирәкле эшләрен ахрына кадәр илтеп җиткерү өчен көчләрен кызганмадылар. Героик котыпчылар Төньяк Боз океанының тикшерелмәгән районнарында гаять зур фәнни эш алып бару өчен хәрәкәттәге карабның бөтен мөмкинлекләреннән файдаландылар.

Арктиканы өйрәнү буенча башка экспедицияләр тарафыннан алынган бай тәҗрибәдән седовчылар яхшы файдаландылар. Фәнни эшнең барлык мәсьәләләре буенча алар Арктика институтындагы галимнәрдән еш кына консультацияләр алдылар. „Төньяк котып" станциясенең 1938 нче елны „Ермак" белән җибәрелгән материалларда хәрәкәтне исәпләүдә седовчыларга зур гына ярдәм итте.

Бозның хәрәкәте „Седов"ны Төньяк Боз океаныннан Гренландия диңгезенә чыга торган урынга алып килгәч, карабны бозлардан чыгаруда ярдәм итү өчен Совет Хөкүмәте шунда ук чара күрде. Бозларга күзәтү ясау өчен Гренландия диңгезенә башта җәнлекләр аулый торган „Мурманец" борты җибәрелде. Хәрәкәттәге караб бозның читенә якынлашкач, аңа ярдәмгә иптәш Папанин җитәкчелегендә куәтле „И. Сталин" бозваткычы чыкты. Гренландия диңгезендә бозларның хәрәкәте турында маглүматлар булганлыктан, совет котыпчылары „Седов"ның бозсыз урынга кайчан һәм нинди урында чыгачагы турында җитәрлек дәрәҗәдә төгәл исәпли алдылар.

Седовчы иптәшләргә мактау һәм дан. Аларның үз-үзләрен аямый эшләүләре алдынгы совет фәненә кыйммәтле хәзинә кертте.

(ТАСС).

Чит илләрдә

ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 8 гыйнвар. (ТАСС). Кичә көндез фронтта әйтерлек бер нәрсә дә булмаганлык турында хәбәр ителә. Төнлә Вогезыдан көнбатыштарак районда патрульләрнең активлыгы сизелде.

БЕРЛИН, 8 гыйнвар. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе иглан иткән сводкада болай диелә:

„Көнбатышта, Мерцигтан көнбатыштарак чик буе өлкәсендә дошманның разведка дозорларының чыгышлары кире кагылды. Дошман югалтуларга дучар ителде".

ЛОНДОН, 8 гыйнвар. (ТАСС). Англиянең 3.317 тонна авырлыгындагы „Сити оф Марсель" пароходы Шотландия ярлары буенда минага бәрелгән. Шартлау нәтиҗәсендә командадан бер кеше үлгән, 13 кеше яраланган.

Бергеннән (Норвегия) 45 миль ераклыкта Германиянең 5.062 тонна авырлыгындагы „Франкенвальд" пароходы батырылган. 48 кешелек команда һәм Норвегиянең ике лоцманы Норвегия эсминецы тарафыннан коткарылган.

Англиянең 5.160 тонна авырлыгындагы „Седрингтон корт" пароходы Англиянең көньяк ярында минага бәрелеп баткан. 34 кешелек команда коткарылган.

БЕРЛИН, 8 гыйнвар. (ТАСС). Декабрьнең икенче яртысында диңгездәге сугыш хәрәкәтләре нәтиҗәсендә Дания 19.669 тонна авырлыгындагы 12 сәүдә пароходын югалткан.

СУГЫШНЫҢ БЕР КӨНЕ ФРАНЦИЯГӘ МИЛЛИАРД ФРАНККА ТӨШӘ

БРЮССЕЛЬ, 8 гыйнвар. (ТАСС). Бельгиянең „Либр бельжик" газетасы Франциянең кораллар министре Дотринең түбәндәге белдерүен иглан итә: „Сугышның бер көне Франциягә бер миллиард франкка төшә; һәрбер минут аңардан 750 мең франк күләмендә расход тотуны таләп итә".

Дотри болай дип өсти: чыннан да, хәзер инде пехотага ярдәм итү өчен җитәрлек булмый башлаган 75 миллиметрлы пушка 300 мең франк тора, эрерәк калибрдагы пушканың бәясе исә бер миллион франк чамасына җитә. Артиллерия полкын коралландыру 50 миллион франкка, танк батальонын коралландыру — 120 миллион франкка төшә. Ләкин иң кыйммәтле корал — зенит орудиеләре, чөнки алар 12 минут буена тиз атып торганнан соң сафтан чыгалар. Сугыш вактында дивизия сәгатенә 5 миллион франклык чамасы сугыш материалы тота. Зенит батареясеннән бер тапкыр ату 5 миллион франкка төшә.

АКШ белән Австралия арасында дипломатия мөнәсәбәтләре урнаштырылу

ВАШИНГТОН, 8 гыйнвар. (ТАСС). АКШ һәм Австралия хөкүмәтләре ике ил арасында дипломатия мөнәсәбәтләре урнаштырылуны иглан иттеләр. Австралиянең АКШ тагы беренче илчесе итеп тәэминат министре Кэсей билгеләнгән. Якын арада Америкадан Австралиягә илче билгеләнәчәк.

Канаданың һәм Көньяк Африка союзының Вашингтонда илчеләре бар. Шулай итеп, хәзер Яңа Зеландия — Англия доминионнары арасында АКШ та дипломатия вәкиле булмаган бердән-бер доминион булып тора.

Ассошиэйтед пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, АКШ белән Австралия арасында дипломатия мөнәсәбәтләре урнаштыру турындагы сөйләшүләр сугышка кадәр үк башланган булган, ләкин сугыш хәрәкәтләренең җәелеп китүе һәм Көнчыгыштагы вакыйгалар бу мәсьәләне хәл итүне тизләткәннәр.

АНГЛИЯ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕНЕҢ СОВЕТЛАР СОЮЗЫ БЕЛӘН ТЕЛӘКТӘШЛЕГЕ

ЛОНДОН, 8 гыйнвар. (ТАСС). Ливерпульдәге университет лейбористлар федерациясе конференциясе Львов университеты студентларын һәм профессорларын, Һиндстан һәм Кытай студентларын котлап резолюция кабул итте.

Манчестер университетының социалистик җәмгыяте дә Советлар Союзының Финляндиядәге хәрәкәтләрен яхшы дип табып резолюция кабул итте.

Шундый ук резолюцияләр профсоюзлар советларының Ланкашир һәм Чешир федерацияләре конференцияләрендә дә кабул ителде. Фикер алышуларда тредюнионнар конгресының политикасын тәнкыйть итеп һәм урыннардагы профсоюзларның җитәкчеләрен котлап күп кенә ораторлар сөйләделәр.

АК ФИННӘРГӘ ЯРДӘМ ИТҮГӘ КАРШЫ

ОСЛО, 8 гыйнвар. (ТАСС). Бөтен Норвегиядә ак финнәргә ярдәм итүгә каршы протест кампаниясе киңәя. Норвегиянең промышленность үзәге Одда шәһәрендә шушы көннәрдә генә күренекле профсоюз эшчесе Артур Берг ак финнәргә ярдәм итүгә каршы протест белән чыкты. Берг болай дип белдерде: „1918 нче елны патша генералы Маннергеймга каршы көрәштә фин пролетариатына ярдәм иткән, Норвегия эшчеләр сыйныфы фин халкы палачына хәзер дә ярдәм итмәскә тиеш".

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Соңгы көннәрдә кытай гаскәрләре Гуандун провинциясенең төньяк өлешендә японнарның вак отрядларын уңышлы рәвештә бетергәннәр. Чаниннан 10 километр көнчыгыштарак Мэйкон янында кытайлар 700 гә якын япон солдатының үле гәүдәсен җыеп алганнар, күп санда кораллар һәм амуниция кулга төшергәннәр. Кытайлар японнарны Кантон—Ханькоу тимер юлы буйлап көньякка таба кысрыклауда дәвам итәләр. Бацзян станциясе янында японнар зур югалтулар ясаганнар.

Англия Гонконгы чиге районында 4 нче һәм 5 нче гыйнварда кытай гаскәрләре Шэньчунны һәм Наньтоуны алганнар. Гуанлун провинциясенең көнчыгыш өлешендә сугышлар Чаочжоудан 15 километр көньяктарак Фынци районында дәвам итә. Монда өч көнгә сузылган сугышлар нәтиҗәсендә 300 дән артык япон солдаты үтерелгән һәм күп санда амуниция һәм кораллар кулга төшерелгән.

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә, Наньниннан көньяктарак кытай гаскәрләре белән япон гаскәрләре арасында сугышлар дәвам итә. Кытайлар күп кенә зур булмаган пунктларны алганнар. Наньнин—Циньчжоу шоссесенең урта участкысын кытай гаскәрләре тәмам җимереп бетергәннәр. Сентрал Ньюс агентлыгы, Цзюйтан районында японнарның 21 нче бригадасы командиры генерал Накамура үтерелгәнлекне хәбәр итә. Аның үтерелүе шулай ук кытайлар тарафыннан пленгә алынган япон солдатларының көндәлек дәфтәрләрендәге язмалар буенча да раслана.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Суйюань провинциясеннән, японнарның бөтен тырышуларына да карамастан, аларның Баотоу белән Гуйхуа арасындагы юлны һаман да рәткә кертә алмаганлыкларын хәбәр итәләр.

„Цзунмейжибао" газетасы, 28 нче декабрьдә японнарның Баотоудагы позицияләренә кытай гаскәрләренең атакалары вактында курчак властьларның Ю Ченмин җитәкчелегендәге солдатлар полкының японнарга каршы восстание күтәргәнлеген хәбәр итә. Восстание күтәрүчеләр япон советнигы полковник Такахасины үтергәннәр һәм Кытай милли хөкүмәтенең Баотоу тирәләрендә хәрәкәт итүче гаскәрләренә кушылганнар.

Шаньси провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә японнарның 10 мең кешелек гаскәрләре авиация һәм артиллерия ярдәме белән Чжанцзы районында һөҗүм башлаганнар. 4 нче гыйнварда һөҗүм тулысынча кире кагылган. Японнарның 3 мең чамасы кешеләре үтерелгән һәм яраланган.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Хубей провинциясенең көньяк өлешендә, Тунчэн секторында кытай гаскәрләре японнарның позицияләренә һөҗүм башлаганнар. Хэнаньның көньягында, Синьян секторында япон частьләре кытай гаскәрләренә каршы ныклы атакалар ясаганнар. Берничә сәгатькә сузылган каты сугыштан соң японнар, 800 чамасы кешеләрен югалтып, элекке позицияләренә чигенгәннәр. Кытайлар японнарның берничә танкларын юкка чыгарганнар.

Педагогика кабинетларының эшләрен яхшыртыйк

1938 нче елны РСФСР Мәгариф Халык Комиссариатының приказы буенча оештырылган район педагогика кабинетлары үзләрен, кыска гына вакыт эчендә, яхшы яктан күрсәтә алдылар. Район педагогика кабинетларының яхшы эш тәҗрибәләре нигезендә, үткән елны Татарстанның да 23 районында мондый кабинетлар оештырылган иде. Педагогика-методика кабинетларының эшләрен тикшерү, аларның практик эшләрен өйрәнү, укытучыларның белемнәрен күтәрү институты тарафыннан күптән түгел үткәрелгән киңәшмә бу кабинетларның зур уңышларга ирешкәнлекләрен күрсәттеләр. Кабинетларның күпчелеге педагогика-методика эшләренең үзәге булып әверелделәр.

Күп кенә район мәгариф бүлекләре, партия райкомнары һәм башка җәмагат оешмалары педагогика кабинетларының эшләренә, аларның балаларны укыту һәм тәрбияләүнең сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән эшләренә зур игтибар бирәләр. Кабинетларның уңышлы эшләүләре өчен барлык шартларны тудыралар, аларны тиешле кадрлар белән туплыйлар. Ютазы районында педагогика кабинеты мөдире булып орденлы укытучы иптәш Рязанова, Чистай районында 45 еллык педагогик стажы булган иптәш Гаев эшлиләр.

Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты, шушы бер еллык эш тәҗрибәсеннән чыгып, 1940 нчы елда тагын 42 районда педагогика кабинетлары оештырырга булды. Кабинетларның эшләре: укытучыларның политик аңнарын һәм падагогик-методик квалификацияләрен күтәрү, иң яхшы укытучыларның һәм мәктәпләрнең үрнәкле эш тәҗрибәләрен өйрәнү һәм аларны укытучыларның киң массасына җиткерү, укытучыларга педагогик һәм методик яктан практик ярдәм күрсәтү буенча бер-берсенә тыгыз бәйләнештә булган шушы өч юнәлештә барырга тиеш.

Район оешмалары укыту-тәрбия эшенең сыйфатын күтәрүдә район педагогика кабинетларның гаять зур әһәмиятле булуларын искә алып, аларга тулы эш шартлары тудырырга һәм барлык чаралар белән булышлык күрсәтергә тиешләр.

Н. Надиев.



Казан яшьләре хәрби-диңгез эшенә өйрәнәләр. РӘСЕМДӘ: Хәрби-диңгез клубында штурманлык эшенә өйрәнү вакты. Сулдан уңга: штурманлык эше укытучысы Е. А. Успенский һәм комсомол кызыл флотчылар И. Г. Лазарев, С. Л. Ильин, А. М. Ниязов һәм П. Г. Константинов.

Б. Мясников фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Җидди темага җиңел шаяру

Әдәби темаларга дискуссияләр—тансык нәрсә. Шуңа күрә 7 нче гыйнварда, Язучылар союзында, „Реализммы яки провинциализммы?" дигән темага билгеләнгән әдәби дискуссиягә язучылар да, шагыйрьләр дә, журналистлар да, укучы яшьләр дә бик кызыксынып килгәннәр иде. Ләкин башта кызыктыргыч төсле булып күренгән бу эш кызыклы ук булып чыкмады. Хәтта бер дә кызыгы булмады. Дискуссия дигәнебез, безнең гади телгә күчереп әйткәндә, яш тәнкыйтьче Г. Халит иптәшнең чираттагы сүгенүе булып кына калды. Чынлап та, бөтен бер елда (сүз 1939 нчы ел турында бара) басылып чыккан, барлык дип әйтерлек, проза әсәрләрен 2—3 сәгат вакыт эчендә пыр туздырып ташларга шактый зур егетлек кирәк! Г. Халит әнә шул егетлекне күрсәтте, ул теге яки бу әдәби әсәрнең нечкәлекләренә, художество үенчәлекләренә кереп үзен мәшәкатьләп тормастан, барсын да дип әйтерлек бер күсәк, үзенең дуамаллыгы һәм үтемсезлеге белән язучылар җәмагатьчелегенә күптән үк таныш булган борынгы күсәк белән кыйнады-кыйнады да, „минем миссиям шуның белән тәмам, егетләр!" дигән сымак итеп трибунадан төшеп тә китте. „Матур туганда" романын бөтенләй юк нәрсә, Гариф Галиевнең җиңел һәм укыр өчен кызыклы итеп язылган 1939 нчы елгы хикәяләрен „Җавапсыз тойгылар күләгәсе", яки өметле яш язучыларыбыздан Мин Шабай, Ф. Басыйр иптәшләрнең хикәяләрен коры обстракциядән торган вактөяк чүп-чарлар итеп кенә калдыру фактын бүтәнчә ничек аңларга кирәк соң? Һич шиксез, бу әсәрләрнең җитешсез яклары күп, ләкин шуның белән бергә аларда укучыны тарта ала торган оригиналь яклар да бар. Тәнкыйтьченең боларны күрмичә үтәргә тырышуы, бигрәк тә, беренче хикәяләре белән үк үзләренә өмет баглата алган яш иптәшләрне „чүпкә чыгарып" ташларга тырышуы гаҗәп хәл. Моннан соң нәрсә турында дискуссия алып барасың инде?! Язучылар, күсәк эләккән җирләрен тотып, мәйданны батырның үзенә генә калдырып, тизрәк чыгып китү ягын карадылар.

Күсәк-күсәк инде ул, күсәкнең җилкәгә акыллы яки акылсыз булып төшүе турында бәхәс алып бару үзе дә күсәклек булыр иде, ләкин шулай да бер нәрсә гаҗәпләндерә: җидди темалар буенча бу рәвешчә җавапсыз һәм җиңел шаяруларга Язучылар союзында кайчан чик куелыр икән? Без дискуссиягә каршы түгел. Киресенчә, без аны яклыйбыз. Ләкин дискуссия саф, намуслы һәм акыллы булырга тиеш. Ул безнең эшебезгә яңалык, дәрт һәм большевистик ачыклык алып килсен.

Киләчәктә әдәби дискуссияләр гомумән булмыйча, конкрет бер нәрсә турында һәм конкрет итеп алдан хәзерләнеп үткәрелергә тиешләр. Югарыда әйткәнебезчә, дискуссияләр эшкә булган дәртне шиндермәсеннәр, ә киресенчә, аны тагын да ныграк көчәйтсеннәр.

Ф. Хөсни.

ФӘТХИ БУРНАШНЫҢ ЯҢА ПЬЕСАСЫ

Фәтхи Бурнаш иптәш Татарстанның XX еллыгына багышлап хәзерге авыл тормышын чагылдырган „Ялгыз Ярулла" исемле яңа пьесасын тәмам итте. Бу пьеса октябрь аенда Татар Дәүләт Академия театрында укылган һәм ул вакыт авторга кайбер теләкләр куелган иде.

Пьесаның соңгы редакциясе 10 нчы гыйнвар кич 8 сәгаттә язучыларның Г. Тукай исемендәге кабинетында укылачак. Җыелышка язучылар, артистлар һәм әдәбият белән кызыксынган иптәшләр чакырылалар.

Луцкиның тарих музее

Волын өлкәсендә күп кенә борынгы һәм революцион тарихи, художестволы һәм этнографик памятниклар бар. Польша паннары бу памятникларны җимереп һәм аларны киң катлау хезмәт ияләре массасыннан яшереп килгәннәр.

Луцк музееның, изүчеләргә каршы халыкның гасырлар буена килгән көрәшен чагылдыручы матур экспонатлары подвалга ташланган булганнар.

Хәзер Луцк тарих музее барлык кыйммәтле әйберләрне яңарту эшенә керешә. Шулай ук гражданнар сугышы елларына караган яңа документлар 56 нчы номерлы „Коммунар" бронепоездының 1920 нче елны Малорита станциясе якынында Польша шляхтасына каршы көрәштә батырларча һәлак булган героик сугышчылары һәм командирлары турында документлар табылды.

„Коммунист" (Украина).

Бакчачылыктан зур доход

Шөгер районының „Шушма" һәм Әлмәт районының „Зәй" колхозлары җиләк-җимеш бакчаларыннан югары уңыш алуга ирешү өчен үткән ел үзара социалистик ярышка чыкканнар иде.

Шушы арада ярыш договорының үтәлешенә йомгак ясалды. Һәр ике колхоз җиләк-җимеш бакчаларының доходлылыгын күтәрү буенча зур уңышларга ирештеләр. Җиләк-җимеш питомнигыннан „Шушма" колхозы 60 мең сум, „Зәй" колхозы 24 мең сум доход алдылар.

Бу колхозлар бакчачылыктан тагын да зуррак доход алу бурычын куеп, быел да үзара социалистик ярышка чыктылар.

Ш. Сәлимҗанов.
„Шушма" колхозы бакчачысы.

Доход бүлделәр

Дөбъяз районының „Передовой" һәм Чапаев исемендәге колхозлары доход бүлделәр. Агротехника чараларын дөрес үткәрү нәтиҗәсендә, „Передовой" колхозы югары уңыш алды. Биредә һәрбер хезмәт көненә 4 килограмм бөртекле ашлык бүленде. Колхозчы Панков семьясе үзенең хезмәт көннәренә 180 пот ашлык алды.

Х. Латыйпов.

Колхоз белгечләре хәзерләү

Татарстан районнарында 26 урында районара колхоз мәктәпләре эшли. Шуларның 13 е кырчылык кадрлары һәм 13 е терлекчелек кадрлары хәзерли.

Мәктәптә хәзер 232 кырчылык бригадиры, 90 яшелчәче, 277 ветеринария фельдшеры, 254 терлекчелек фермалары мөдирләре, 171 умартачы һәм башкалар укый.

1 нче февральдән мәктәптә 2 нче наборда кабул ителгән, колхоз белгечләре укый башлаячаклар. Монда бәрәңге һәм яшелчә эшкәртүче 60 бригадир, 60 атчылык фермасы мөдирләре, 90 кырчылык белгечләре һәм башкалар укыячак.

ЯҢА МАГАЗИН АЧЫЛДЫ

Кызыл Йолдыз районы үзәгендә район магазины ачылды.

Раймагка 140 мең сумлык тегелгән төрле өс киемнәре, мануфактура һәм башка күп кенә товарлар кайтты. Раймаг 3 көн эчендә 69 мең сумлык товар сатты.

Сәйфетдинов.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

С. М. КИРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ
КАЗАН ХИМИКО-ТЕХНОЛОГИЯ ИНСТИТУТЫ
институтка хәзерлек буенча 6 айлык
— курсларга остәмә рәвештә —
УКУЧЫЛАР АЛА

Курсларга тегәлләнгән урта белемле (10 еллык мәктәп, техникум, рабфак тегәлләгән) кешеләр алыналар.

Хәзерлек курсларында укулар производстводан аерылмыйча алып барыла.

Гаризалар, ВУЗ ларга керү өчен сорала торган документлар белән, шушы ел 22 нче гыйнварга кадәр, институтның кадрлар бүлегендә һәр көн иртән 9 сәгаттән кич 9 га кадәр алына.

Казан, Карл Маркс урамы, 68. Телефон 14—98. 37—3—1

Шәһәрара Казан Телефон станциясендә
расписание һәм тәртип үзгәрешләре:

1. Казан белән Чувашстан АССР ның үзәк шәһәре Чебоксар арасында телефон буенча сөйләшү вакты моңа кадәр булган 2 сәгат 30 минуттан 11 сәгатькә кадәр озайтылды һәм бу шәһәрләр арасында телефон буенча сөйләшү өчен 2 сәгаттән 5 сәгатькә, 10 сәгаттән 10 сәгат 30 минутка, 12 сәгаттән 16 сәгатькә, 20 сәгаттән 21 сәгатькә һәм 21 сәгат 30 минуттан 24 сәгатькә кадәр булган вакытлар билгеләнде.

2. Төнге сәгатьләрдә (0 сәгаттән 7 гә кадәр) сөйләшүләр өчен нормаль тарифтан 50 процент ташлама ясала.

3. Шәһәрара сөйләшү өчен заказларны квартира телефоны буенча бирергә, шулай ук шәһәрара телефон станциясенә килмичә, квартира телефоны буенча сөйләшергә мөмкин. Расчет эшләре телефон станциясе биргән счетлар буенча үткәрелә.

Шәһәрара Казан Телефон станциясе.
38—1

ТАТАРСТАН АССР НАРКОМПРОСЫ ЯНЫНДАГЫ
ЧИТТӘН ТОРЫП УКУ ЗУРЛАР МӘКТӘБЕ
5, 6, 7, 8, 9 ҺӘМ 10 нчы КЛАССЛАРГА
УКУЧЫЛАР АЛА

Мәктәп производстводан аерылмыйча үзлегеннән уку юлы белән, тулы булмаган урта һәм урта мәктәп программалары буенча экстерн рәвештә экзамен бирү өчен хәзерләнергә мөмкинлек бирә. Мәктәпкә 16 дан түбән булмаган яштәге кешеләр алыналар.

Читтән торып укучыларга ярдәмгә группалы һәм индивидуаль консультацияләр оештырыла. Уку кирәк-яраклары бирелә.

Гаризалар һәр көн эш сәгатьләрендә 1940 нчы ел 1 нче февральгә кадәр алына.

Гариза белән бергә, керүченең белеме турында документ, хезмәте урыныннан белешмә һәм кабул ителгән үрнәктәге анкета бирелергә тиеш.

Читтән торып уку мәктәбенә керүчеләрдән—5 нче класска керүчеләр рус теленнән һәм арифметикадан, ә башка классларга керүчеләр шул класстан түбәнге классның программасы буенча барлык предметлардан сынаулар үтәләр.

Мәктәптә укудан тукталган кешеләр, укудан тукталуга 3 елдан артык булмаса, сынаусыз алыналар.

Сынаулар 1 нче февральдән, ә укулар 20 нче февральдән башлана.

Адрес: Казан, Кремль, Татнаркомпрос, 5 нче бүлмә. Телефон: Кремль, 22.

Татарстан АССР районнарында торучылар гаризаларны Арча, Әтерҗе, Аксубай, Актаныш, Этнә, Акташ, Бөгелмә, Буа, Кукмара, Куйбышев, Лаеш, Мамадыш, Норлат, Минзәлә, Мөслим, Чаллы, Алабуга, Тәтеш, Шөгер һәм Чистай районнарында консультация пунктларына (урта мәктәпләр янында) бирәләр.

Тулы мәгълүматларны РОНО дан алырга мөмкин.

Дирекция.
2697—3—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 10 нчы гыйнварда
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Талон 73.
11, 12 һәм 13 нче гыйнварда М. Ю. Лермонтовның тууына 125 ел тулуга багышланган юбилей спектакльләре
МАСКАРАД
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТГОСФИЛАРМОНИЯ
Киров районындагы КУЛЬТУРА САРАЕНДА 10 нчы гыйнварда Филармония талоннары: 42 һәм 43
КЫЗЫЛ АРМИЯ ЙОРТЫНДА 11 һәм 12 нче гыйнварда Талоннар: 11 ндә 30, 31 һәм 12 ндә 32 һәм 33
ССР Союзының Ленин орденлы Дәүләт Академик Зур театры солисты
Я. И. ЕНАКИЕВ
концертлары
Моннан элек иглан ителгән концертларда файдаланылмаган талоннар белән дә (кассага күрсәтеп) кертелә. 47—1

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Тулысынча яңа программа
Москва 4 нче труппасының
гастрольләре
Бөтен труппа катнаша.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

Татар Дәүләт Опера театры
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
11 нче гыйнварда
КАЧКЫН
Талон 63.
Кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Культпоходлар оештыру буенча заявкалар алына. Телефоннар: 29—04 һәм 30—78.
48—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген һәм иртәгә спектакльләр булмый.
12 нче гыйнварда көндез (талон 93)
ГАЕПСЕЗДӘН ГАЕПЛЕЛӘР
Кич (талон 94)
КЫЮ КЫЗЛАР
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 11-45, 1-45, 3-45, 5-45, 7-45 һәм 9-45 тә.	Көндез 10 сәгаттә ҺАВА ПОЧТАСЫ һәм башка сеансларда УКЫТУЧЫ
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	УКЫТУЧЫ Көндез 10 сәгаттә балалар өчен сеанс
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	Көндезге сеансларда МИТЬКА ЛЕЛЮК Кич УКЫТУЧЫ
„ЧАТКЫ" 6, 8 һәм 10 да.	СЕНТЯБРЬДӘГЕ ТӨН
„ПИОНЕР" 11, 2, 4, 5-45 8, һәм 10-15 тә	Көндезге сеансларда ПАРТИЗАН КЫЗЫ Кичке сеансларда БӨЕК ГРАЖДАНИН (икенче сериясе) Көндез 1 сәгаттә мәктәпкәчә тәрбия яшендәге балалар өчен сеанс
„РОТ-ФРОНТ" 10, 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	Бөек бүләк
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	ХАРАКТЕРЛЫ КЫЗ

Елемтә идарәсенең транспорт конторасына өлкән бухгалтер, сварщик, җыештыручылар, пич ягучы һәм авто эшләре буенча слесарьлардан 10 кеше кирәк. Казан, Фуксовский урам, 28. Телефоннар 26—83 һәм 32—80.
2568—2—2

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 2479 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 119.